**ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул.Дмитрова, д.2, с.Ютаза, 423962**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
**Дмитров урамы, 2 йорт, Ютазы авылы, 423962**

**Тел.:(85593) 4-00-91, факс:4-00-93, e-mail: Utaz.Utz@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» ноябрь 2024 ел № 9

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге составына керүче Малиновка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмәгә таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 19 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Малиновка торак пункты, Болын урамы, 3 санлы йорт адресы буенча урнашкан торак пункт янында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Малиновка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2025 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге Малинвока торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы:

- Малиновка торак пунктында зират территориясен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эш өчен килешү буенча түләү);

- Малиновка торак пунктында авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, эш өчен килешү буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Малиновка авыл җирлеге башкарма комитетына Керкәле торак пунктында граждannar җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хәйруллина